# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**13.11.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2020 елның 13 ноябрендә 10.00 сәгатьтә үткәрелгән гражданнар җыенының «2021 елда 400 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авылы Мортыштамак авыл җирлеге территориясендә I төркем инвалидлардан; көндезге бүлектә укучы студентлардан,ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме:

1)Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан су башнясының хуҗалык корылмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) янгын ранецлары (2 данә), су салу өчен емкость (1 т), янгын җиңсәләре (2 данә)сатып алу;

3)кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Мортыштамак авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары (бензин), хуҗалык эшләре өчен инвентарь (көрәк, тырма,сәнәк, себеркеләр) сатып алу;

5) Мортыштамак авылы Совет урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт сатып алу ,ташу,чокырларга асфальт түшәп ремонтлау, асфальт җәю, эш өчен түләү);

6) Мортыштамак авылында Минзәлә елгасы аша салынган күперне ремонтлау (буяу сатып алу);

7) Мортыштамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

8) Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан зират территориясендәге биек агачларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрдән чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

9) ял итү зоналарын төзекләндерү (Мортыш елгасы һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлар өчен куелган обелиск янында эскәмияләр, урналар сатып алу һәм урнаштыру ;

10) яңа юл билгеләре урнаштыру өчен металл торбалар сатып алу;

11) Мортыштамак авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу.

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучылар исемлегенә сайлау хокукына ия булган 324 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны - 254 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
гражданнар җыенында «РИЗА» позициясе өчен 250 катнашучы тавыш бирде; «КАРШЫ» позициясе өчен 4 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак авылы торак пунктында гражданнар җыенын узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип таныргa.

2. «2021 елда 400 сум күләмендә Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авылы территориясендә I төркем инвалидлардан; ашыгыч хәрби хезмәт үтүче гражданнардан ; көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү өчен үзара салым кертергә килешәсезме » дигән сорау буенча карар кабул итәргә:

1)Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан су башнясының хуҗалык корылмасын ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

2) янгын ранецлары (2 данә), су салу өчен емкость (1 т), янгын җиңсәләре (2 данә)сатып алу;

3)кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

4) Мортыштамак авылы территориясендәге чүп үләннәрен чабу һәм җыештыру (ягулык-майлау материаллары (бензин), хуҗалык эшләре өчен инвентарь (көрәк, тырма,сәнәк, себеркеләр) сатып алу;

5) Мортыштамак авылы Совет урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (асфальт сатып алу ,ташу,чокырларга асфальт түшәп ремонтлау, асфальт җәю, эш өчен түләү);

6) Мортыштамак авылында Минзәлә елгасы аша салынган күперне ремонтлау (буяу сатып алу);

7) Мортыштамак авылы урамнарын яктырту объектларын карап тоту һәм хезмәт күрсәтү (лампалар, энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм урнаштыру);

8) Мортыштамак авылы Совет урамында урнашкан зират территориясендәге биек агачларны, куакларны кисү, яшь үсентеләрдән чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);

9) ял итү зоналарын төзекләндерү (Мортыш елгасы һәм Бөек Ватан сугышында һәләк булган авылдашлар өчен куелган обелиск янында эскәмияләр, урналар сатып алу һәм урнаштыру ;

10) яңа юл билгеләре урнаштыру өчен металл торбалар сатып алу;

11) Мортыштамак авылында спорт ярышлары уздыру өчен призлар, бүләкләр сатып алу.

3. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен Мортыштамак авыл җирлегенең Мортыштамак мәгълүмати стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:/ https://sarmanovo.tatarstan.ru/), хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының Мортыштамак авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге башлыгы,
Халык җыенында рәислек итүче И.Н.Хадиуллин